# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** 05.12.2019 ел

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль
районының Шуган авыл җирлеге составына керүче
Рус Шуган торак пунктына 2020 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлеге Рус Шуган торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Рус Шуган торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә. Көндезге формада укучы студентларга, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга катнашучыларга 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- Рус Шуган авылы мәдәният оешмаларының ялын оештыру һәм анда яшәүчеләрне хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;
- Физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итү, Рус Шуган авылы җирлегендә рәсми спорт чараларын үткәрүне оештыру;
- Рус Шуган авылы җирлегендә рәсми мәдәни-массакүләм чаралар үткәрүне оештыру;
- Рус Шуган авылы җирлеген төзекләндерүне оештыру;
- Рус Шуган авылында ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;
- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, Рус Шуган авылы суларын чыгаруны оештыру;
- Рус Шуган авылы җирлегенең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге;
- Рус Шуган авылы халкының күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру
- Рус Шуганы авыл халкын элемтә, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру».

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда, Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы, Рус Шуган авылы, Ленин урамы, 18а йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Шуган авыл җирлеге башлыгы** **А.Ю.Басорина**